ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№__352__ от «_18_»____05____2018 г.

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының опекунлык
һәм попечительлек өлкәсендә
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ
регламентларын яңа редакциядә раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210 - ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатыннан, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 20 март, 2008 ел, № 7 ТРЗ Татарстан Республикасы законы, “Опека һәм попечительлек турында” 24 апрель, 2008 ел, № 48- ФЗ Федераль закон , “Россия Федерациясе территориясендә балаларны уллыкка (кызлыкка) тапшыру һәм уллыкка (кызлыкка) алучылар гаиләләрендә аларның тормышы һәм тәрбия шартларына контрольлек итү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе гражданнары булып торучы һәм чит ил гражданнары яки гражданлыксыз затлар тарафыннан уллыкка (кызлыкка) алынган балаларны Россия Федерациясе консуллык учреждениеләрендә учетка кую кагыйдәләрен раслау турында” 29 март, 2000 ел, № 275 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (РФ законнар җыентыгы, 2000 ел, №15, 1590 ст; 2012,№19 2416 ст; №21 2644 ст; № 37, 5002 ст; 2013, № 7,661 ст.; № 28, 3829; 2014 №7, ст.687; 2015, № 38, 5289 кертелгән үзгәрешләрдән чыгып); Россия Федерациясе Хөкүмәтенең « Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны гаиләгә урнаштыру мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе Хөкүмәтнең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында " 2017 елның 30 декабрендәге 1716 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Ресубликасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү хакында” 2010 ел, 2 ноябрь 880 нче санлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы вәкиллекле органның 2013 ел, 8 ноябрь. 6-21 санлы карары, Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә

таянып, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Яңа редакциядә раслarga:

1.1. Ятим балалар өчен булган оешмаларда тәрбияләнүче балаларны, ата- ана тәрбиясеннән мәхрүм балаларны Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнар гаиләләренә вакытлыча тапшыру мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба- дәүләт хезмәте) (1 нче санлы кушымта).

1.2. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче балигъ булган гражданнарга уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү һәм уллыкка алучы сыйфатында исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (2 нче санлы кушымта).

1.3. Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче гражданнарга (түләүле һәм түләүсез шартларда ятим балалар, ата- ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өстеннән опекунлык (попечительлек) билгеләү яки опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (3 нче санлы кушымта).

2. “Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында” 07.09.2016 ел, 1087 нче санлы карары белән расланган 10, 12, 15 санлы кушымталарны гамәлдән чыккан дип таныйрга.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының матбугат һәм массакүләм чаралары белән хезмәттәшлек секторына опека һәм попечительлек билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентларын өч көн эчендә интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов